# ХӘБӘРЧЕ 34

безгә 1976 елдан ышаналар

Выпуск #6

Бу номерда:
ТАССР төзелүгә 100 ел
Без татарча өйрәнәбез
ШАЯН ТВ да кунакта
Күренекле кешеләр



ТАТАРСТАН

# ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ 100 ЕЛ!

Без Татарстан җирендә яшибез. Татарстан – ул безнең Туган илебез, торган җиребез, туган йортыбыз. Туган җир һәр кешегә газиз, кадерле. Аның зифа каенлы урманнарын, көмеш сулы күлләрен, балык белән тулы киң елгаларын бик яратабыз. Татарстан табигате белән генә түгел, үзенең табигый байлыгы белән дә дан тота. Иң зур байлыгыбыз – ул «кара алтын». Республикабыз җире табигый газ, ташкүмер, торф, төзелеш материалларына да бай. Татарстан – бәйсез дәүләт. 1990 нчы елның 30 нчы августында Татарстанның мөстәкыйльлеге, бәйсезлеге хакында Декларация һәм 1992 нче елның 6 нчы ноябрендә Конституциябез кабул ителде, 1994 нче елның 15 нче февралендә Шартнамәгә кул куелды.

*Туган җирем! Матур таңнар*  
*Иленә тиңлим аны.*  
*Ул – минем Татарстаным,*  
*Бар татарның Ватаны.*

Татарстан җире – татар халкының борынгы, тарихи туган иле. Татарстанда якынча 4 миллион кеше, ул күп милләтле республика. Безнең халкыбыз киң күңелле, республикабызда 107 милләт вәкиле яши. Монда күп кенә башка милләтләр үзләренең икенче туган илләрен тапканнар. Татар халкы гасырлар дәвамында рус, чуаш, мари, башкорт, мордва, удмурд һәм башка халыклар белән туган җиребезне тагын да матурлау өчен хезмәт иткәннәр. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә,"тел лөгать, гадәт вә ахлак алмашып" яшәгәннәр. Татарлар башка милләт кешеләре бер гаилә кебек бергәләшеп эшлиләр, дус яшиләр.

*Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,*  
*Дуслар кирәк һәрбер кешегә.*  
*Дуслык булса яшәү дә күңелле,Җавап.*  
*Уңай була һәрбер эшең дә.*

***Әдһәмова Камилә,***  
***8А сыйныф укучысы***

**“Кем күбрәк белә?”**

**Сорау:** Татарстанның беренче президенты кем? — Минтимер Шаймиев

**Сорау:** Беренче дүрт хәрефе русча “әни” сүзенә туры килә. Бу нинди район? — Мамадыш районы

**Сорау:** Татарстандагы иң кечкенә район ничек дип атала? — Әтнә районы

**Сорау:** Татарстанның башкаласы нинди шәһәр? — Казан

**Сорау:** Казандагы иң зур мәчет ничек дип атала? — Кол Шәриф мәчете

**Сорау:** Г. Тукайның татарларның гимнына әверелгән шигыре ничек дип атала? — Туган тел

**Сорау:** Татар халкының милли бәйрәме нинди? — Сабантуй

**Сорау:** Милли татар ризыгы ничек дип атала? — Чәк-чәк

**Сорау:** Кремль нинди елга буенда урнашкан? — Казансу




# БЕЗ ТАТАРЧА ӨЙРӘНӘБЕЗ!

Ә син татар телен яхшы беләсеңме? Башлангыч сыйныф укучылары бу сорауга, һичшиксез, «**әйе**», дип җавап бирәчәк. Чөнки алар «**Сәлам!**» яңа буын татар теле дәреслеге буенча белем ала. Татар һәм рус балаларын татарча иркен аралашырга өйрәтү – шушы дәреслекнең һәм аның авторларының төп максаты. Татар теле дәреслеге, беренче чиратта, укучыны кызыксындыра торган булырга тиеш. Җитмәсә, ул һәркемгә аңлашылсын, гади дә, кулланырга уңайлы да булсын. “Сәлам” дәреслеген ни өчен балалар ярата соң? Хәзер без сезгә кыскача аңлатма биреп китәрбез.



Рус мәктәбендә белем алучы рус һәм татар балаларына татар теле укыту шактый катлаулы эш. Бигрәк тә башлангыч этапта балаларда татар сөйләменә, гомумән, татар теленә кызыксыну уяту бик мөһим. Хәзерге рус телелек заманында кайбер татар балалары да рус балаларыннан әллә ни аерылмый. Күбесенчә гаиләдә рус телендә сөйләшеп үскән бала татарча җөмләләрне кабул итә, аңлый алмый азаплана. Шул сәбәпле, минемчә, һәр ике төркемдә дә телне бала күңеленә иң якын булган уен аша җиткерү отышлырак.

Балалар дөньясы – бик үзенчәлекле, бик җанлы, кызык дөнья. Алар эшсез, хәрәкәтсез тора алмыйлар. Шулай булмасалар, балалар җитез, сәләтле, нык һәм ихтыяри көчле кеше булып үсә алмаслар иде. Алар, берничә бала бер җиргә җыелдымы, шунда ук бер уен оештыру ягын карыйлар. Ял сәгатьләрендә аларның иң күңелле һәм файдалы шөгыльләре шул уеннар була. Димәк, уен – иҗтимагый шөгыль һәм балага зарури әйбер ул.

Рус төркемнәрендә туган тел дәресләрен без “**Сәлам**” методикасы белән укытабыз. Ул методика буенча дәресләр уен формасында алып барыла. Мәсәлән, 1 нче сыйныфларда “**Кайтаваз**”, “**Балык**”, “**Бу нәрсә?**”, “**Кар өеме**”, “**Утыр, киттек**” уеннары; 2 нче сыйныфларда “**Туп**”, “**Пантомима**”, “**Баскетбол**”, “**Кәләпүш**” уеннары; 3-4 нче сыйныфларда шул уеннар кабатлана, ныгытыла. Дәресләрне балалар бик яраталар, теләп йөриләр.

Татар теле дәресенә кызыксынуны арттыру өчен дәресләрдә төрле **көйләр һәм җырлар** кулланырга була. Җыр күңел ачу моменты гына түгел, лексик запасларны арттыру, грамматик конструкцияләрне яхшырак үзләштерү чарасы да. Ул сүзне әйтү күнекмәләрен ныгыта, эстетик кабул итүгә тәэсир итә, коллективны туплый. Сыйныфта яхшы психологик климат урнаша, эмоциональ тонус арта. Без дәресләрдә бик теләп бу алымны кулланабыз.

Җырлар махсус шушы дәреслек өчен язылган. Аларны Айгөл Әюпова иҗат иткән. Интернет булмаган очракта җырларны өйрәнү, аудиоларны тыңлау өчен дисклар да каралган.



## *Сәлам җыры*

*Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!*
*Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!*
*Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!*
*Сау бул, дустым! Хәерле көн!*

*Сәлам, сәлам! Хәерле көн!*
*Сәлам, сәлам! Хәерле көн!*
*Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!*
*Сау бул, дустым! Хәерле кич!*

*Сәлам, сәлам! Хәерле кич!*
*Сәлам, сәлам! Хәерле кич!*
*Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!*
*Сау бул, дустым! Тыныч йокы!*

# ШАЯН ТВда КУНАКТА



Февральнең ямьле көннәрендә «Йолдызлар» һәм «Алтын ай» командалары «Тамчы шоу» интеллектуаль телевизион бәйгесендә катнаштылар.

«Бөтенебез дә бик озак әзерләндек. Кемдер дөньяның җиде могҗизасын өйрәнде, кемдер кыргый хайваннар темасына керде, ә кайберәүләр сүзлекләр аша татар сүзләрен ятлады», - дип уен турында тамашачылар сөйли.

Ильназ Мифтахов, Камилә Әдһәмова һәм Камилла Мифтахова «Йолдызлар» составына керделәр. Команданың җитәкчесе – Ильназ, кызлар белән бергә, бернидән дә курыкмыйча, искиткеч уен күрсәтте, сорауларның җаваплары тиз табылды. «Алтын ай» командасына Розалия Сафиуллина, Рәсим Закиров һәм Рәсил Мубаракшин керделәр. Билгеләр буенча алар икенче урынга лаек булдылар.

Уен дүрт бүлектән торды. Беренчесендә борынгы һәм хәзерге дөньяның җиде могҗизасын табырга кирәк иде. Кызлар (Камилә һәм Розалия) һәр 14 сорауга дөрес җавап бирделәр, шуңа күрә баштан командалар тигез бардылар. Икенче турда бөтен команда катнашырга тиеш иде: танылган кешеләр инстаграм аша сораулар бирделәр, ә катнашучылар тиз генә җавап табырга тиеш иде. Бу бирем җиңел булды, әмма “Алтын ай”лар берничә балл югалттылар.

Өченче турда Ильназ һәм Рәсим уйнады. 30 секунд эчендә бер тематик сорауларга «әйе» яисә «юк» дип җавап бирергә кирәк иде. Рәсимгә кыргый хайваннар, ә Ильназга гомуми белем буенча сораулар эләкте. Икесе дә озак уйламыйча, сорауларга дөрес җавап бирделәр. Алай да, Ильназ бер балга алга чыкты. Иң кызыгы дүртенче турда булды: сүзтезмәләрдән төшеп калган сүзләрне язырга кирәк иде. Бу юлы ике команда да лексиканы яхшы белде, шуңа күрә балл арасында аерма булмады. Уен, әлбәттә, җиңел түгел иде, кемгәдер ул дәрес булып күренде. Беркем дә үпкәли калмады, барысына уен бик охшады.



Фото: «Акыл баттл» уены



Фото: «Акыл баттл» уены





ТНВ каналында уңышлы гына эшләп килгән «Тамчы-шоу» интеллектуаль уенда без инде беренче тапкыр гына катнашмыйбыз. Бу юлы безнең 7 нче сыйныф укучылары көч сынашты. Алар үзләренең белемнәрен тиешле дәрәҗәдә күрсәттеләр дип уйлым. Киләчәктә дә без ТНВ каналы белән хезмәттәшлекне дәвам итербез дип өметләнәм.

Безнең мәктәп укучылары бик теләп интеллектуаль бәйгеләрдә катнаша. ТНВ каналының балалар өчен чыгучы «Шаян» каналы оештырган «Акыл баттл»да да, «Тамчы шоу»да да беренче тапкыр гына катнашмыйлар. Быелгы бәйгенең үзенчәлекле ягы – танылган шәхесләр тарафыннан бирелгән сораулар булуы. Сораулар логик фикерләүгә корылган, укучылар өчен бик кызык булды. Үзләренең татар телен камил белүләрен тагын бер исбатлап кайттылар. Афәрин, укучылар! Алда да зур уңышлар сезгә.



# КҮРЕНЕКЛЕ КЕШЕЛӘР





Сөембикә



Габдельжаббар Кандалый


Кол Гали


Фатих Амирхан


Габдулла Тукай


Абдулла Алиш


Һади Такташ


Каюм Насыйри


Муса Җәлил

## 34KAZANSCHOOLMEDIA ТАТАР РЕДАКЦИЯСЕ:

**Авторлар:**
Адгамова Камиля
Мифтахов Ильназ
Зиннатуллина Алсу
Исхакова Камиля
Хасанова Азалия
Зиннатуллина Рената

**Дизайн:**
Рябова Александра

**Корректор:**
Березкина Гульназ Талгатовна

**Шеф-редактор:**
Гимадеева Нурия Рашидовна

**Верстка:**
Загидуллин Рамиль

**Дата:** 26 февраля 2021

**Адрес:**
420066, ул. Короленко, 26
34KazanSchoolMedia
татар редакциясе

**Вакытлылык:**
айга 1 мәртәбә

**Тираж:**
30 экземпляр

**КАЗАН 2021**